КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1276

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

58 пунктта «А.1.1. күрсәткече» сүзләрен төшереп калдырырга;

59 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«59. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең һәм эффективлыгының индикатив күрсәткечләре:

1) хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.»;

бу Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Күпфатирлы йортлар белән
идарә итү буенча эшмәкәрлек
эшчәнлеген гамәлгә ашыруга
төбәк дәүләт лицензия контроле
турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 24 декабрь, 1276 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең
күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген
гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контролен гамәлгә ашырырга
вәкаләтле вазыйфаи затлары (дәүләт торак инспекторлары)
исемлеге

1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – баш дәүләт торак инспекторы.

2. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарлары – баш дәүләт торак инспекторы урынбасарлары.

3. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – Хокук идарәсе башлыгы.

4. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасарлары – районара һәм Казан шәһәр торак инспекцияләре башлыклары.

5. Үзәк инспектор бүлеге башлыгы.

6. Үзәк инспектор бүлеге башлыгы урынбасарлары.

7. Үзәк инспектор бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.

8. Үзәк инспектор бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

9. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге башлыгы.

10. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе.

11. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге әйдәп баручы консультанты.

12. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.

13. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлеге башлыгы.

14. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе.

15. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлеге әйдәп баручы консультанты.

16. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезлелеген тикшерү бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.

17. Торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгы.

18. Торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе.
19. Торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.
20. Аналитика һәм контроль секторы мөдире.
21. Аналитика һәм контроль секторының 1 нче разрядлы өлкән белгече.
22. Казан шәһәр торак инспекциясе башлыгы урынбасары.
23. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге башлыгы.
24. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге консультанты.
25. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.
26. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле бүлеге 1 нче разрядлы белгече.
27. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге башлыгы.
28. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге консультанты.
29. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.
30. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр бүлеге башлыгы.
31. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр бүлеге консультанты.
32. Казан шәһәр торак инспекциясенең торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр бүлеге әйдәп баручы белгеч-эксперты.
33. Районара торак инспекциясе консультанты.
34. Районара торак инспекциясе әйдәп баручы белгеч-эксперты.
35. Районара торак инспекциясенең I разрядлы белгече.